**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрэч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрэч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» гыйнвар, 2021 ел № 19

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2009 елның 14 февралендәге 266 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында»

Питрәч муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны җайга салу һәм идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы чикләрендә билгеләнгән чикләрдә транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр бирүдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 13 гыйнварындагы 09/13-09/49 номерлы хатын, Питрәч муниципаль районы Уставын үтәү йөзеннән, Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Субсидияләр бирү тәртибенең 4.1 пунктына түбәндәге сүзләр өстәргә:

- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.Р. Байгильдинга йөкләргә.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин